**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ"УРМАНДЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

№ 3 13.11.2025ел

«Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге
Урмандеево авылында гражданнарның үзара салым кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Урмандеево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә КАРАР :

1.20.11.2025 елда 14 сәгать 00 минутка Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Урмандеево авылында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Урмандеево авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, юлларны кышкы карап тоту шартнамә буенча эшләр өчен түләү )

**2) ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту**
- традицион күмү урыннарын төзекләндерү (материаллар сатып алу) , койма тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Җыеннарны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылыкны Урмандеево авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Урмандеево авыл җирлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә: http://aksubaevo.tatar.ru
5. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Урмандеево авыл җирлеге башлыгы: В.З.Николаев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРМАНДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ